РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.09.17 г. Бугульма № 973

**Татарстан Республикасы “Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең “Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә “Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчасына) балаларны исәпкә кую һәм исәпкә алу” муниципаль хезмәтен күрсәтү**

# АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 “Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә “Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчасына) балаларны исәпкә кую һәм исәпкә алу” муниципаль хезмәтен күрсәтү административ регламенты (алда - Админстратив регламент) мәктәпкәчә яшьтәге балаларны исәпкә кую һәм аларны ТР “Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә төп гомуми белем программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына күчерү тәртибен билгели (алда – муниципаль хезмәт).

1.2 Хезмәт күрсәтүне 2 айдан 7 яшькә чаклы балаларның ата-анасы (яки башка законлы вәкилләре) булган Россия Федерациясе гражданнары, Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче чит ил гражданнары ала.

Төп гомуми белем программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (алда – Оешма) чираттан тыш урнашу хокукына ия:

- Судьялар балалары;
- Прокурорлар балалары һәм Тикшерү комитеты хезмәткәрләре балалары;
- Чернобыль АЭСындагы һәлакәт һәм аларга тиңләштерелгән гражданнар категорияләре нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнар балалары;

- Һәлак булган (Хәбәрсез югалган), үлгән, инвалид булган хезмәткәрләр һәм Россия Федерациясе Төньяк Кавказ регионында хезмәт итүче гаскәрләрнең берләштерелгән төркеме һәм террорчылык эшчәнлеген ачыклау һәм туктату буенча махсус көчләр хәрбиләренең балалары;
- Хәрби хезмәт итүчеләр, эчке эшләр органнары хезмәткәрләре, янгынга каршы дәүләт хезмәте, турыдан туры Дагестан Республикасы территориясендә террорчылыкка каршы көрәштә катнашкан җинаять башкарма системасы һәм

**Татарстан Республикасы “Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең “Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә “Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчасына) балаларны исәпкә кую һәм исәпкә алу” муниципаль хезмәтен күрсәтү Административ регламентын раслау турында**

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министырлыгының №под-1049/17 09.06.07 “Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының якынча формасына үзгәрешләр кертү турында” боерыгы нигезендә”, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министырлыгы 10.03.2015 №1389/15 “Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчасына) балаларны исәпкә кую һәм исәпкә алу”, Федераль закон 06.10.2003 № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең Уставы раславы буенча, муниципаль хезмәтләрне бирү сыйфатын арттыру максатында:

1. “Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә “Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчасына) балаларны исәпкә кую һәм исәпкә алу” муниципаль хезмәтен күрсәтү административ регламентына тиешле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. “Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә “Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчасына) балаларны исәпкә кую һәм исәпкә алу” муниципаль хезмәтен күрсәтү административ регламентының яңа редакциясенең расларга.

3. “Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчасына) балаларны исәпкә кую һәм исәпкә алу” муниципаль хезмәтен күрсәтү админисратив регламентын раслау буенча” 20.09.2016 №177 Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитет җитәкчесе карарын үз көчен югалткан дип санарга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары – Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе җитәкчесе Кульбеда В.В.

**Вазыйфаларын**
**башкаручы-урынбасар** **В.В. Гарафетдинов**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ